Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ул. А.Валеева, д. 53, село Ильбяково,
Азнакаевский район, 423321

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авылы
җирлеге башкарма комитеты

А.Валеев урамы, 53нче йорт, Илбәк авылы,
Азнакай районы, 423321

Тел. (факс) 8(85592) 38-5-38; e-mail: Ilb.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» июнь 2017 ел. №8

"Шәхси мәгълүматлар турында"
2006 елның 27 июнендәге 152-ФЗ номерлы
Федераль законда каралган бурычларны
үтәүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру турында

"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июнендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 152-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм "шәхси мәгълүматлар турында "Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларда каралган бурычларны үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген раслау хакында" 21.03.2012 елгы 211 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, карар бирәм:

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында шәхси белешмәләрне эшкәртү кагыйдәләре (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында субъектларның яисә аларның вәкилләренең шәхси белешмәләрдән файдалану өчен соратуларын карау кагыйдәләре (2 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында шәхси белешмәләрне эшкәртүнең шәхси белешмәләрне яклауга карата таләпләргә туры килүенә эчке контрольне гамәлгә ашыру кагыйдәләре (3 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында шәхси белешмәләр шәхессез калган очракта шәхессез белешмәләр белән эшләү кагыйдәләре (4 нче кушымта);
- Муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси белешмәләр эшкәртелә торган биналарга керү тәртибе (5 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм затларның шәхси белешмәләрне эшкәртүне йә шәхси белешмәләрдән файдалануны гамәлгә ашыруны күздә тоткан вазыйфалары исемлеге (6 нчы кушымта);

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында шәхси белешмәләрне эшкәртүне оештыру өчен җаваплы вазыйфаи затның вазыйфаи регламенты (7 нче кушымта);
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге башкарма комитетына:
- муниципаль хезмәткәрләрне әлеге карар һәм Үрнәк рәвешләр белән таныштыру (шәхси белешмәләрне эшкәртү кагыйдәләренә 1-3 нче кушымталар);
- муниципаль хезмәткәрләргә (хезмәткәрләргә) Россия Федерациясе законнарының шәхси белешмәләрне эшкәртүгә бәйле таләпләрен үтәмәүнең хокукый нәтиҗәләрен аңлатырга;
- муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты хезмәткәрләренең Россия Федерациясенең шәхси белешмәләр өлкәсендәге норматив хокукый актлары белән танышуы;
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси белешмәләрне эшкәртүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәткәрләре (хезмәткәрләре) тарафыннан, алар белән хезмәт контракты яисә хезмәт шартнамәсе өзелгән очракта, вазыйфаи (хезмәт) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа билгеле булган шәхси белешмәләрне эшкәртүне туктату йөкләмәләрен рәсмиләштерү;
- муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә һәм вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрләрнең (хезмәткәрләрнең), шулай ук башка субъектларның шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалык рәсмиләштерү;
- муниципаль хезмәткәрләргә (хезмәткәрләргә) Россия Федерациясенең шәхси белешмәләрне эшкәртүгә бәйле законнары таләпләрен үтәмәүнең хокукый нәтиҗәләрен аңлату һәм шәхси белешмәләрне бирүдән баш тартуны аңлатуны рәсмиләштерү чараларын үткәрү.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина